**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“24” ноябрь 2019 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлегенең Югары Сәрдә торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә авылы территориясендә 2020 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлегенең Югары Сәрдә авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1. Авыл җирлеге биләмәсе территориясен чистарту тәртипләрен раслау, аларның үтәлешен тәэмин итү, территорияне төзекләндерүне билгеләнгән кагыйдәләргә таянып оештыру:

- Югары Сәрдә авылы территориясендәге агач һәм куакларны кисү, чистарту.

2. Күмү урыннарын төзекләндерү һәм карап тоту:

- Югары Сәрдә авыллы зираты территориясендәге агач һәм куакларны кисү, чистарту;
- Югары Сәрдә авыллы зираты коймасы өчен материалар алу.

3. Авыл җирлеге биләмәсе чикләрендәге автомобиль юлларын төзекләндерү эшләре:

- Югары Сәрдә авылы юлларыны түшәү өчен вак таш алу һәм транспорт өчен түләү.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлегенең Югары Сәрдә авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Югары Сәрдә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Сәрдә авыл җирлеге башлыгы Хуснутдинов Р.Р.